

# НАБИУЛЛИН
# НАИЛ ХАБИБУЛЛОВИЧ
# (1939-2016)

Шагыйрь, үзешчән композитор, прозаик, драматург, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Бөтен гомерен сәнгатькә, мәдәнияткә, иҗатка багышлап, тормышны, халыкны, халыкның дөньясын сөеп яшәүче шагыйрь, үзешчән композитор, күп санлы хикәяләр һәм пьесалар авторы, һәрвакыт иҗат дәрте белән янучы Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, “Ядкәр”, "Тормыш дәрьясы", “Китмә яшьлек”, “Яшәү яме” исемле китаплар иясе Наил Хәбибулла улы Нәбиуллин.

Автобиография

Мин, Нәбиуллин Наил Хәбибулла улы, Татарстанның элекке Биләр районы (хәзер Алексеевск) Зур Тигәнәле авылында 1939 елның 25 февралендә туганмын. Җидееллык белемне авыл мәктәбендә алдым, аннан күрше авылга йөреп урта мәктәптә укыдым. Армия хезмәтеннән соң, 1960 елда Алабуга мәдәният училищесына укырга кердем. Училищеның оркестр бүлеген тәмамлагач, 1964 елда Әгерҗе районына эшкә җибәрделәр. 1964 елдан мәдәният йорты инструкторы, 1965 елдан методист, 1970 елдан директор булып эшләдем. Бу елларда мин райондагы барлык мәдәният йортларының эше һәм кешеләре белән тирәннән таныштым, аларның иҗат коллективларының эшен, материал базаларын өйрәндем һәм зур тәҗрибә тупладым. Клуб һәм мәдәният йортларына һәрвакыт методик һәм практик ярдәм күрсәттем, семинарлар, практикумнар оештыруда турыдан туры катнаштым.

1974 елдан 1996 елга кадәр район Мәдәният бүлегендә инспектор хезмәтен башкардым. Үзем эшләгән чорда мин район Мәдәният йортында оркестр, хор, ансамбльләр оештырдым, спектакльләр куйдым. Район иҗат коллективларының эшен яхшы оештырган өчен Республика һәм Бөтенсоюз фестивальләре лауреаты исеменә лаек булдым һәм медальләр алдым. Шигырьләр, җырлар язу белән яшьтән үк мавыктым. “Сандугач сайрый талларда” җырын 1955 елда ук язган идем. Төрле елларда язган шигырьләрем җыелып килде һәм 1996 елда Әгерҗе типографиясендә “Ядкәр” исемле шигырьләр китабы бастырып чыгардым. Шигырьләр һәм җырлар язуымны хәзер дә дәвам итәм. Девятернә авыл Мәдәният йорты хезмәткәре Фәнис Арсланов минем уннан артык шигыремә көйләр язды. Шуларның иң уңышлыларының берсен “Авылымны сагынам” җырын Татарстанның халык артисты Салават Фәтхетдинов үз репертуарына кертте. Шулай ук “Девятернәм”, “Авылда – туган ягымда”, “Әниемә бүләк” һәм башка җырларны Фәнис үзе даими җырлап килә. Минем сүзләргә “Алар һаман сине

көтәләр", "Чишмә моңы", "Гөлфиям" җырларын Кодаш урта мәктәбе укытучысы Равил Бадахшин язды һәм ул җырларның республика фестивальләрендә дә башкарылганы бар.

Тирсә урта мәктәбе укытучысы Фәния Мөхәммәтшина да берничә шигыремә җыр язды.

Шуларның берсе: "Калырсың моң булып" исемле. Минем үземнең дә, үз шигырьләремә һәм башка авторларның шигырьләренә язган җырларым бар: "Иж буеның айлы кичләре" (Габдулла Галиев шигыре), "Кырынды авылы", "Очар идем" (Наилә Галиева, шигыре), "Бәйкием", "Әүлия чишмәсе" җырларының сүзләрен һәм көйләрен үзем яздым. Шулай ук "Саубуллашу" исемле лирик вальсым бар. "Ай кызы" исемле әкият – пьесам Әгерҗе районы сәхнәләрендә үзешчәннәр тарафыннан халыкка җиткерелде.

## Наил Набиуллин

Родился 25 февраля 1939 года в селе Тиганали Алексеевского района. С малых лет любил участвовать в художественной самодеятельности. В 1961 поступил в Елабужское культпросветучилище. После окончания оркестрового отделения был направлен в Агрызский район. С 1964 года работал в РДК методистом, директором. Затем долгие годы был на должности инспектора отдела культуры. В это же время начал литературную деятельность. Его стихи печатались на страницах районной газеты. В последние годы стихи печатались в газете «Яңарыш». В 1996 году вышел сборник стихов «Ядкарь». Сочинял музыку, им написаны песни на свои стихи и стихи местных поэтов.

**Библиография:**

Ядкәр: шигырьләр, җырлар. - Әгерҗе район типогр., 1996.-64б.

Үз моңым бар җирдә: шигырьләр.-Әгерҗе: Яр Чаллы типогр., 1996.-24б. (Авылымны сагынам, Бәйкием: җырлар Н.Нәбиуллин).

Күңел чишмәләре: Татарстан Республикасының Әгерҗе төбәгендә яшәп иҗат итүче шагыйрьләрнең шигырьләр җыентыгы, Ижау; Ижевская респ. Типогр., 1998.-318 с.

Яшьлегем гөлләре: Шигырь// Яңарыш.-2002.-14 июль.-12б.

Нәбиуллин Н. Тормыш дәрьясы: Җыентык/ Әгерҗе үзәкләштерелгән китапханәләр системасы үзәк китапханәсе; Нәбиуллин Н.Х.- 2010.-184 бит.

Нәбиуллин Н.Х. Китмә, яшьлек: җыентык/ Әгерҗе үзәкләштерелгән китапханәләр системасы үзәк китапханәсе.-2012.- 44 бит.

Нәбиуллин Н.Х. Яшәү яме: җыентык/ Әгерҗе үзәкләштерелгән китапханәләр системасы үзәк китапханәсе. – 2016.-37 бит.

**Аның турында:**

Шәрипов Р. Мәдәнияткә багышланган гомер// Яңарыш. – 1999.-№9.-6 б.

Хәбәрчеләр: Яшьлегемә кире кайтыр идем. Ниләр булды.: Шигырьләр: 65 еллык юбилее алдыннан: Иҗатына бер караш// Әгерҗе хәбәрләре.-2004.-28 февраль.-7 бит.